| | |
|---|---|
| **СОВЕТ**<br>**Исенбаевского сельского поселения**<br>**Агрызского муниципального района**<br>**Республики Татарстан** | **Татарстан Республикасы**<br>**Әгерҗе муниципаль районы**<br>**Исәнбай авыл җирлеге**<br>**СОВЕТЫ** |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

03.02.2023 Исәнбай авылы № 29-1

Әгерҗе муниципаль районы Исәнбай авыл җирлеге Советының "Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының "Исәнбай авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәне раслау хакында" 31.01.2019 елның 48-1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль норматив-хокукый актларны хокукый мониторинг нәтиҗәләре буенча Россия Федерациясе законнарына туры китерү максатларында, "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Исәнбай авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. "Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының "Исәнбай авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәне раслау хакында" 31.01.2019 елның 48-1 номерлы Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Исәнбай авыл җирлеге Советының карарына кертелә торган үзгәрешләрне расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Исәнбай авыл җирлегенең мәгълүмат стендында игълан итәргә, "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru).
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Совет Рәисе,
Авыл җирлеге башлыгы Ф.Ф. Сираев

Татарстан Республикасы Әгерҗе
муниципаль районы Исәнбай авыл җирлеге
Советының 2023 елның 3 февралендәге 29-1
номерлы карары белән расланды

"Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының "Исәнбай авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәне раслау хакында" 31.01.2019 елның 48-1 номерлы Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Исәнбай авыл җирлеге Советы карарына кертелә торган үзгәрешләр

1. 28.1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 5 пункт өстәргә:
"5) муниципаль хезмәткәрләргә чит ил агенты статусы алу.".
2. 11.1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 11 пункт өстәргә:

   "11) аларга чит ил агенты статусы алу.".

3. 20 пунктның 4 пунктчасында "мәҗбүри пенсия иминияте системасында" сүзләрен "мәҗбүри пенсия иминияте һәм мәҗбүри социаль иминләштерү системаларында," сүзләренә алмаштырырга.

4. 11.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

   "11.4 Җирле үзидарә органы, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппараты җитәкчесе булган муниципаль хезмәткәр, күрсәтелгән муниципаль хезмәткәрнең мәнфәгатьләр конфликтын төшереп калдыру максатларында әлеге җирле үзидарә органының сайланулы профсоюз органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында алар тиешле вазыйфаны биләгән чорда муниципаль хезмәткәрләр мәнфәгатьләрен тәкъдим итә алмыйлар.".